| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
| СОВЕТ<br>Нижнекамского муниципального района | Түбән Кама муниципаль районы<br>СОВЕТЫ |
| 423570, г.Нижнекамск, пр.Строителей,12<br>факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41 | 423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12<br>факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41 |

| | |
|---|---|
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |
| № 49 | 2020 елның 20 мае |

**Түбән Кама муниципаль районы Советының 2005 елның 29 декабрендәге 25 номерлы «Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең бюджет-финанс сәясәте буенча нигезләмәләрен раслау турында» карарының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында**

«2020 елның 1 апрелендәге 103-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору һәм 2020 елда федераль бюджетны үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 1 статьясы нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. 2021 елның 1 гыйнварына кадәр Түбән Кама муниципаль районы Советының 2005 елның 29 декабрендәге 25 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең бюджет-финанс сәясәте буенча нигезләмәләрнең 17 статьясындагы 2 пункты, 29 статьясындагы 10 пункты, 35 статьясындагы 4 пунктының 13 абзацы, 42 статьясындагы 1 пункты, 47 статьясындагы 4 пункты (бюджет үтәлеше турында еллык хисапка бәяләмәләр әзерләү сроклары өлешендә), 47 статьясындагы 7 пункты (сроклар өлешендә) гамәлен туктатып торырга.

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны социаль-икътисади үсеш, бюджет-финанс мәсьәләләре һәм муниципаль милек буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль<br>районы Башлыгы — А.Р.Метшин

ПРЕДСТАВИТЕЛЬНЫЙ ОРГАН
ВӘКИЛЛЕКЛЕ ОРГАН